**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Илбәк авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Илбәк авылы № 9 30 сентябрь 2015 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының 16.01.2012 № 30 карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Илбәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында (24.09.2012 №44, 05.08.2013 №63, 22.10.2014 №100 карарлар редакциясендә)

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Илбәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставын җирле үзидарә турындагы федераль һәм республика законнарына туры китерү максатларында

Илбәк авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының 16.01.2012 № 30 карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Илбәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына (24.09.2012 №44, 05.08.2013 №63, 22.10.2014 №100 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 6 статьяда:

1.1.1 өлешнең 7 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7) җирлек территориясендә физик культураны, мәктәп спортын һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тудыру, җирлекнең рәсми физкультура-савыктыру һәм спорт чараларын үткәрүне оештыру;"

1.1.2. 1 статьяда түбәндәге эчтәлекле 14-19 пунктчалар өстәргә:

«14) каты коммуналь калдыкларны җыю (шул исәптән аерым-аерым җыю) һәм транспортировкалау эшчәнлеген оештыруда катнашу;

15) ритуаль хезмәт күрсәтүләрне оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту;

16) җирлек чикләрендә Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, суны чыгаруны, халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру;

17) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге;

18) милләтара һәм конфессияара татулыкны ныгытуга, җирлек территориясендә яшәүче Россия Федерациясе халыкларының телләрен һәм мәдәниятен саклап калуга һәм үстерүгә, мигрантларның социаль һәм мәдәни адаптациясенә, милләтара (этникара) конфликтларны профилактикалауга юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру;

19) җирлек халкының күпләп ял итүе өчен шартлар тудыру һәм халыкның күпләп ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыру, моңа гражданнарның гомуми файдаланудагы су объектларына һәм аларның яр полосаларына ирекле керүен тәэмин итү дә керә. "

7 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 12, 13 пунктчалар өстәргә:

«12) федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда оешмалар хезмәт күрсәтүләренең сыйфатын бәйсез бәяләүне оештыру өчен шартлар тудыру;

13) җирлек территориясендә яшәүче хуҗасыз йорт хайваннарын аулау һәм асрау чараларын гамәлгә ашыру. "

10 статьяда «Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт турында» 2008 елның 17 гыйнварындагы 5-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы» сүзләрен «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы» сүзләренә алмаштырырга.

23 статьяның 4 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Гражданнардан сорашып белешүне билгеләү һәм үткәрү тәртибе әлеге Устав һәм (яисә) җирлек Советының норматив хокукый актлары белән Татарстан Республикасы законы нигезендә билгеләнә. "

1.5 статьяда:

1 өлешнең 3 пунктчасының өч абзацында «, шул исәптән сатып алу юлы белән,» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.5.2. 1 өлешнең 4 пунктчасына түбәндәге эчтәлекле дүртенче абзац өстәргә:

«- җирлекнең коммуналь инфраструктурасы системаларын комплекслы үстерү, җирлекнең транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү, җирлекнең социаль инфраструктурасын комплекслы үстерү программаларын эшли һәм гамәлгә ашыра, аларга карата таләпләр Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә. »;

1.5.3. 1 өлешнең 5 пунктчасына түбәндәге эчтәлекле унынчы - ундүртенче абзацлар өстәргә:

«- каты коммуналь калдыкларны җыю (шул исәптән аерым-аерым җыю) һәм ташу эшчәнлеген оештыруда катнаша;

- җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, суны чыгаруны, халыкны ягулык белән тәэмин итүне Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә оештыра;

- җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген оештыра;

- милләтара һәм конфессияара татулыкны ныгытуга, җирлек территориясендә яшәүче Россия Федерациясе халыкларының телләрен һәм мәдәниятен саклап калуга һәм үстерүгә, мигрантларның социаль һәм мәдәни адаптациясенә, милләтара (этникара) конфликтларны профилактикалауга юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыра;

- җирлек халкының күпләп ял итүе өчен шартлар тудыра һәм халыкның күпләп ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыру, моңа гражданнарның гомуми файдаланудагы су объектларына һәм аларның яр полосаларына ирекле керүен тәэмин итү дә керә. "

1.5.4. 6 пунктчага түбәндәге эчтәлекле алтынчы абзац өстәргә:

«ритуаль хезмәтләр күрсәтүне һәм күмү урыннарын карап тотуны оештыра. »;

1 өлешнең 7 бүлегенең сигезенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- җирлек территориясендә физик культураны, мәктәп спортын һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тәэмин итә, җирлекнең рәсми физкультура-савыктыру һәм спорт чараларын үткәрүне оештыру;».

65 статьяның 8 өлешенә түбәндәге эчтәлекле алты, җиде абзацлар өстәргә:

«Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда веб-адрес буенча хокукый акт текстын урнаштыру: http://pravo. tatarstan.ru. ;

- хокукый акт текстын Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында веб-адрес буенча «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру: http://aznakaevo. tatarstan.ru».

1.7. 67 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җирлек милкендә түбәндәгеләр булырга мөмкин:

1) әлеге Уставның 6 статьясында билгеләнгән җирлекнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итү өчен билгеләнгән мөлкәт;

2) җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән мөлкәт, федераль законнарда һәм Россия Федерациясе субъектлары законнарында билгеләнгән очракларда, шулай ук «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлешендә каралган тәртиптә аларга тапшырылган җирле үзидарә органнарының аерым вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән мөлкәт;

3) җирлек Советының норматив хокукый актлары нигезендә җирле үзидарә органнары һәм районның вазыйфаи затлары, муниципаль хезмәткәрләр, муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр хезмәткәрләре эшчәнлеген тәэмин итү өчен билгеләнгән мөлкәт;

4) җирлекнең җирле үзидарә органнарына федераль законнар белән бирелгән һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләргә кертелмәгән мәсьәләләрне хәл итү өчен кирәкле мөлкәт;

5) әлеге Уставның 7 статьясы нигезендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен билгеләнгән мөлкәт, шулай ук «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясындагы 1 һәм 1.1 өлешләре нигезендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән мөлкәт.

2. Җирлекнең әлеге статьяның 1 өлеше таләпләренә туры килми торган мөлкәткә милек хокукы барлыкка килгән очракта, күрсәтелгән мөлкәт мөлкәтне үзгәртергә (мөлкәтнең максатчан билгеләнешен үзгәртергә) яисә читләштерергә тиеш. Мондый мөлкәтне читләштерү тәртибе һәм сроклары федераль закон белән билгеләнә. "

72 статьяның 7 өлешендәге алтынчы абзацында «(муниципаль программалар проектларында, күрсәтелгән программаларга үзгәрешләр проектларында) сүзләрен өстәргә. "

1.9. 81 статьяның 2 өлешендә «муниципаль сайлауларда сайланган» сүзләрен төшереп калдырырга, «составына керә» сүзләрен «рәисе вәкаләтләрен башкара» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарның 1.1.2 пунктының икенче, дүртенче, бишенче, алтынчы, җиденче абзацлары, 1.5.3 пункты 2016 елның 01 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәве өчен җибәрергә.

4. Әлеге карарны Азнакай муниципаль районының Илбәк авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә һәм веб-адрес буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: http//aznakayevo. tatastan.ru.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис Л.Р. Әсәдуллина